# Мин бит татар баласы

Дөньяны галимнәр ача,
Килә галим буласым.
Гел бишлегә дип тырышам
Мин бит татар баласы!
Кемгәдер ярдәм кирәксә,
Йөгреп кенә барасы.
Ярдәмчел буласым килә
Мин бит татар баласы!
Ялкау түгел, эш яратам,
Килә йортлар саласым.
Бәхетне эштә табармын, -
Мин бит татар баласы!
Һәрвакыт та дуслар кирәк,
Чын дусларны табасы.
Дуслар янында югалмам, -
Мин бит татар баласы!